СОВЕТ СОКОЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.38, с.Соколка,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422181

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОКОЛКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 38 нче йорт, Соколка авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422181

тел.(факс): (85563) 3-82-05; e-mail: Sokol.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 2-8 от “10” июнь 2016 ел

«Соколка авыл җирлеге территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыюны, алып китүне, утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 17 июлендәге 1-36 номерлы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип тану турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законнар, Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2016 елның 11 апрелендәге № 10-614в-2016/3 протесты, муниципаль берәмлек Уставы нигезендә Соколка авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. « Соколка авыл җирлеге территориясендә көнкүреш һәм сәнәгать калдыкларын җыюны, алып китүне, утильләштерүне һәм эшкәртүне оештыру турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2009 елның 17 июлендәге 1-36 номерлы Мамадыш муниципаль районының Соколка авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Сокол авыл җирлеге башлыгы вазифаларын башкаручы Р.Р. Зиннатовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Соколка авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Р.Р.Зиннатов/